ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
IV чакырылыш
423740, Актаныш авылы, Ленин пр.,
17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
IV созыва
423740, село Актаныш, пр. Ленина,
дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
**20 нче май 2025 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№45-06**

Актаныш муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 09 ноябрендәге 41-15 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 20 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2019 елның 09 ноябрендәге 41-15 номерлы карары (11.09.2020 ел, №48-04, 31.05.2024 ел, №36-08 карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1.** 8.1 пунктта «яисә башка федераль законнар, һәм гавами сервитут» сүзләрен «һәм (яисә) башка федераль законнар, һәм (яисә) гавами сервитут» сүзләренә алмаштырырга;.

**1.2. 5.7 пунктның 8 абзацын үз көчен югалткан дип танырга;**

**1.3.** 5.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: “Бу вакытта дәүләт яисә муниципаль мөлкәт әлеге Федераль законда һәм (яисә) башка федераль законнарда, һәм (яисә) гавами сервитут белән каралган чикләүләргә дучар ителергә мөмкин.”;

**1.4.** 4.15 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлар «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 1 пунктының 1, 1_1, 5, 9 һәм 10 бүлекчәләрендә каралган ысуллар белән гамәлгә ашырыла торган дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлардан тыш, «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтта әлеге карарлар кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә ачык кулланылышта урнаштырылырга тиеш;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Совет рәисе Л.Р.Зарипов